**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

10.04.2018 № 266

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы
муниципаль программаларының эшләү, тормышка ашыру
һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179 нчы маддәсе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында" 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нчы карары нигезендә һәм Башкарма комитет муниципаль программаларын камилләштерү һәм нәтиҗәлелеген күтәрү максатыннан

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы муниципаль программаларының эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслаРга. (1 нче кушымта).

2. Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты структур бүлекләре муниципаль программаларын әлеге расланган Тәртип нигезендә эшләп гамәлгә куярга.

3. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А.С. Әхмәтшин

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының

2018 ел, 10 апрель, 266 номерлы

карарына 1 нче кушымта

# Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы муниципаль программаларының эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү Тәртибе

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге, муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү Тәртибе (алга таба-Тәртип), Россия Федерациясе Бюджет кодексына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октяберендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында” 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нчы карарына нигезләнеп чыгарыла.

1.2. Әлеге Тәртиптә кулланылучы төшенчәләр:

- муниципаль программа астында әлеге Тәртиптә Татарстан Республикасы Нурлат мунципаль районы Башкарма комитеты катнашында җирле бюджет хисабына гамәлгә ашырыла торган программа күз алдында тотыла. Муниципаль программалар максатлар, ресурслар һәм үтәлү вакытын үз эченә ала, җитештерү, иҗтимагый-икътисади, оештыру-хуҗалык һәм башка чаралар белән тыгыз бәйле, Нурлат муниципаль районының муниципаль, икътисади, экологик, иҗтимагый-мәдәни үсешен нәтиҗәле хәл итүгә юнәлтелә;

- муниципаль программаларны эшләүнең тарафдарлары Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты (хокукый һәм шәхси затлар белән хезмәттәшлек итүдә);

- муниципаль программа заказчысы (муниципаль заказчы – координатор) - Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты, муниципаль программа үтәлеше, эш өчен түләүне тәэмин итү буенча җаваплы;

- муниципаль программаны гамәлгә куючылар – бюджет һәм бюджеттан тыш чараларны алырга, закон тарафыннан расланган рәвештә тиешле гамәлләрне үтәргә хокуклы бюджет һәм башка төрдәге оешмалар.

1.3. Муниципаль программа үз кысаларындагы төгәл бурычларны хәл итүгә юнәлдерелгән берничә ярдәмчел программаны үз эченә алырга мөмкин. Муниципаль программаның ярдәмчел программаларга бүленүе, хәл ителәсе мәсьәләләрнең катлаулылыгыннан һәм масштабыннан, чишү юлларын нәтиҗәле оештыру кирәклелегеннән чыгып, гамәлгә ашырыла.

1.4. Методик яктан җитәкчелек итү, эшкәртүне координацияләү һәм муниципаль программаларны гамәлгә ашыру әлеге Тәртипкә нигезләнеп башкарыла.

1.5. Муниципаль программаны гамәлгә ашыру вакыты проблема, көтелгән нәтиҗә һәм ресурс мөмкинлекләренә карап билгеләнә. Әлеге программаларны иң кимендә өч елга эшләргә тәкъдим ителә.

Муниципаль программаларны эшләү һәм раслау шушы Тәртипнең беренче номерлы кушымтасына нигезләнеп эшләнә һәм үз эченә түбәндәге этапларны ала:

- муниципаль программаны эшләү;
- муниципаль программаның проектын килештерү;
- муниципаль программаның проектына экспертиза үткәрү, шулай ук бәйсез экспертлар белән дә (кирәк булганда);
- муниципаль программаны раслау.

## 2. Муниципаль программаны формалаштыру

2.1. Муниципаль программа тубәндәге бүлекләрдән тора:

- шушы Тәртипнең икенче номерлы кушымтасына нигезләгән муниципаль программаның паспорты;
- мунинципаль программа чишүгә юнәлдерелгән проблеманың характеристикасын ачу;
- муниципаль программаның вакытларын һәм этапларын үз эченә алган төп максатлар һәм бурычлар, ярдәмчел программаның, программа чараларының һәм аларның бурычлары киселешендә нәтиҗәләрне бәяләү индикаторларының кыскача исемлеге һәм тасвирламасы;
- муниципаль программаның ресурслар белән тәэмин ителеше нигезләмәсе;
- муниципаль программаны гамәлгә ашыру механизмы, үз чиратында үз эченә программа белән идарә итү механизмын да кертә;
- муниципаль программаның икътисади, социаль, экологик нәтиҗәлелегенә бәя;
- муниципаль программаның бюджет нәтиҗәлелегенә бәя.

2.2. Муниципаль программаның эчтәлегенә карата түбәндәгеләр таләп ителә.

Муниципаль программаның беренче бүлеге проблемалар исемлеге, аларны нигезләү, һәм, шул исәптән, аларның ни сәбәпләр аркасында барлыкка килүе, шул сәбәпләрне нигезләүдән торырга тиеш.

Муниципаль программаның икенче бүлеге максатларның җәелдерелгән формулировкасыннан һәм программаның бурычларыннан, ярдәмчел программалар исемлегеннән һәм чаралардан, бурычларны хәл итүне тормышка ашыру тәкъдимнәреннән һәм куелган максатларга ирешүне таләп итүдән, һәр чараны тормышка ашыру өчен кирәкле мәгълүматларны (финанс чыганакларга нигезләп) һәм үтәлү вакытын күрсәтеп, программаның нәтиҗәсен бәяләү индикаторын ачыклаудан торырга тиеш.

Программаның максатларына таләпләр:

- спецификациялелек (муниципаль заказчыларның компетенциясе муниципаль программаның максатларына туры килергә тиеш);

- үтәлешлелек (максатлар башкарып чыгарлык булырга тиеш);

- үлчәмлелек (нәтиҗәләрне бәяләп булырга тиеш);

- куелган сроклар белән тәңгәллек (муниципаль программада аерым максатларның үтәлү вакыты һәм этаплары курсәтелгән булырга тиеш).

Бүлектә программа формалаштырган максатларны үтәү өчен куелган бурычларны нигезләү, максатларның үтәлү вакыты, программа үтәлешенең төп этапларын гамәлгә ашыру, һәр этапның планлаштырылган прогноз индикаторы күрсәткечләре һәм һәр этапның бурычлары, шулай ук, муниципаль программаның вакытыннан алда үтәлешен үз эченә алу булырга тиеш.

Муниципаль программа максатының һәм бурычларының үтәлү нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары шушы Тәртипнең өченче кушымтасында күрсәтелә.

Муниципаль программанын өченче бүлегендә еллар буенча һәм финанслау чыганакларына бүленеп, ресурс белән тәэмин итү нигезләнә. Моннан тыш, бу бүлектә бюджеттан тыш акча җәлеп итү мөмкинлеге яки мөмкин булмавы һәм программа чараларын үтәргә муниципаль берәмлекләрнең бюджет акчаларын җәлеп итү мөмкинлеге һәм акчаны җәлеп итүнең төп механизмнары тасвирлана. Муниципаль программаның дүртенче бүлегенә төп таләпләр шушы Тәртипнең бишенче бүлегендә күрсәтелгән.

Муниципаль программаның бишенче бүлегендә программаны тормышка ашырганда килеп чыгарга мөмкин булган иҗтимагый, икътисадый һәм экологик нәтиҗәләр, шулай ук муниципаль программаның бюджет нәтиҗәлелеген бәяләү тасвирлана.

2.3. Муниципаль программада катнашучылар муниципаль программаның алар тарафыннан тормышка ашырыла торган төп чараларга һәм ярдәмчел программаларга кагыла торган өлешенең проектына килешү төзиләр. Муниципаль программага ярдәмчел программа керткәндә, ярдәмче программа заказчысының вәкиле белән килешү төзү дә җитә (берничә заказчы булганда, ярдәмче программа координаторы белән).

Муниципаль программаның төп катнашучылары белән килешенгән муниципаль программа проектын һәм аңлатма язуын муниципаль программаның муниципаль заказчысы (координатор) Нурлат муниципаль районы финанс-бюджет Палатасына һәм Башкарма комитетның территориаль үсеш бүлегенә юллый. Тәкъдим ителгән материалларда муниципаль программаның проектын анализлау, үзвакытында программаны гамәлгә ашыру, нәтиҗәлелеген бәяләү һәм эш барышын контрольдә тоту өчен кирәкле мәгълүматлар булырга тиеш.

2.4. Муниципаль программаны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә бюджет ассигнованиеләре күләме бюджет буенча район сессиясе карары белән раслана һәр муниципаль программага тиешле бюджет чыгымнарының максатчан статьясы турында һәм муниципаль программаны раслаган Башкарма комитеты карары нигезендә билгеләнә.

2.5. Муниципаль программалар район бюджеты турында сессия карары нигезендә үз көченә кергән көннән 2 айдан да соңга калмыйча гамәлгә ашырылырга тиеш.

3. Муниципаль программага экспертиза һәм бәяләмә.

3.1.Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты территориаль үсеш бүлеге һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы финанс-бюджет Палатасы, муниципаль программаның проектын бәяләгәндә, төп игътибарны түбәндәгеләргә юнәлтә:

- программа чараларының нигезләнгән булуы, комплекслылыгы һәм экологик куркынычсызлыгы, үтәлү сроклары;
- финанслау күләмнәренең нигезләнүе;
- муниципаль программаны гамәлгә ашыру өчен бюджеттан тыш акчалар җәлеп ителүе;
- муниципаль программаның үтәлеш механизмының нәтиҗәлелеге;
- муниципаль пограмманың тулаем алганда социаль–иктисади нәтиҗәлелеге, программаны тормышка ашырудан соң көтелгән ахыргы нәтиҗәләре һәм җирлектәге халыкның тормыш сыйфаты күтәрелү бәяләмәсенә йогынтысы.

3.2. Муниципаль программаларның проектлары бәяләү узганнан соң Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты территориаль үсеш бүлеге һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы финанс-бюджет Палатасы карары белән кирәк очракта шулай ук махсус (билгеле бер өлкәдә махсус белемнәр таләп иткән сорауларны өйрәнү) һәм экспертиза узарга тиешләр.

Муниципаль программаларның проектларына бәйсез экспертиза Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе билгеләгән эшче төркем тарафыннан уздырыла, монда конкурс нигезендә бәйсез экспертлар катнаша. Муниципаль программаларның проектларына бәйсез экспертиза үткәрүнең чыгымнарын муниципаль заказчы җирле бюджет чыганакларыннан финанслый.

Әлеге Тәртип буенча каралган экспертиза барышында муниципаль программаларның проектларының куела торган таләпләргә туры килүе билгеләнә, кирәк булган очракта, муниципаль программаларның проектларын эшләп бетерү буенча тәкъдимнәр формалаша.

Муниципаль программа проекты каралганда һәм кабул ителгәндә махсус һәм бәйсез экспертизаларның нәтиҗәләре исәпкә алына.

3.3. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты территориаль үсеш бүлеге һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы финанс-бюджет Палатасы белән берлектә муниципаль программа проектын алганнан соң ике атна эчендә бәяләмә әзерлиләр.

3.4. Муниципаль программа проекты барлык җитешсезлекләр дә бетергәннән соң килешенгән булып санала һәм Башкарма комитеты җитәкчесенә раслау өчен җибәрелә.

## 4. Муниципаль программаларны финанслау.

4.1 Расланган муниципаль программалар җирле бюджет һәм бюджеттан тыш чыганаклар хисабына тормышка ашырыла.

4.2. Муниципаль программада җирле, федераль һәм республика бюджетыннан акча каралган булырга мөмкин.

4.3. Муниципаль программаларны финанслау өчен тотыла торган бюджеттан тыш чараларга: программаны гамәлгә куюда катнашучыларның кертемнәре, монда дәүләт оешмасы һәм дәүләтнеке булмаган оешма һәм предприятиеләр дә керә; программаны гамәлгә ашырудан файда күргән предприятиеләрнең максатчан кертемнәре; банк кредитлары, фонд акчалары, иҗтимагый оешмалар һәм башка керемнәр керә.

4.4. Муниципаль программаны гамәлгә ашыру өчен махсус фондлар оештырыларга мөмкин. Әлеге фондларга юллана торган акчаларның чыганаклары булып: оешма-предприятие карамагында калган табыш, Нурлат муниципаль районының бюджет һәм бюджеттан тыш акчалары һәм башка чыганаклар булырга мөмкин.

## 5. Муниципаль программаларны гамәлгә ашыру буенча идарә һәм аның үтәлешен контрольдә тоту.

5.1. Муниципаль программаны гамәлгә ашыру буенча идарәнең ысуллары һәм формалары муниципаль заказчы белән билгеләнә.

Программада муниципаль заказчының-координаторның һәм муниципаль программаны башкаручыларның, программаны тормышка ашыру вакытлары һәм күләмнәре өлешендә, үзара бәйләнешлеге чагылырга тиеш.

Муниципаль программаны гамәлгә ашыру, гамәлдәге федераль законга таянып, муниципаль программаның заказчысы һәм программа чараларын гамәлгә ашыручы һәрбер башкаручы белән муниципаль ихтыяҗларны канәгатьләндерү өчен продукция алуга һәм тәэмин итүгә кабул ителгән муниципаль контрактлар (шартнамәләр) нигезендә башкарыла.

Муниципаль программаларның муниципаль заказчысы Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты территориаль үсеш бүлеге һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы финанс-бюджет Палатасына муниципаль программаны гамәлгә куючылар белән төзелгән барлык килешүләр хакында хәбәр итә.

5.2. Муниципаль программаны башкаручы, чираттагы финанс елына бүленеп бирелә торган муниципаль программаның финанс чараларын исәпкә алып, ел саен максат индикаторларын, муниципаль программаны гамәлгә ашыру өчен чыгымнарны, муниципаль программаны гамәлгә ашыру механизмнарын һәм аны башкаручылар составын аныклый.

5.3. Муниципаль программага яңа ярдәмче программалар өстәү һәм аларны раслау муниципаль программаларны эшләп чыгару һәм гамәлгә ашыруны билгеләгән тәртиптә башкарыла.

5.4. Муниципаль программаларны башкаручылар Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты территориаль үсеш бүлеге һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы финанс-бюджет Палатасына программаларның эш барышын тормышка ашыру һәм финанс чараларын кулануның нәтиҗәлелеген турында мәгълүматны юнәлтәләр.

Еллык гомуми хисапка үтәлми калган чаралар турында мәгълүмат та теркәлергә тиеш.

5.5. Еллык хисап әлеге Тәртипнең 4 нче кушымтасы билгеләгән форма буенча тутырылган статистик мәгълүматны һәм түбәндәге бүлекләрдән торган аналитик мәгълүматны үз эченә ала:

а) хисап тоту чорында ирешелгән төгәл нәтиҗәләр;

б) билгеләнгән вакытта башкарылган һәм башкарылмаган эшләр (сәбәпләрен күрсәтеп), чаралар исемлеге;

в) муниципаль программаны тормышка ашыру барышына йогынты ясаган факторларның анализы;

г) чаралар үтәлү өчен бюджет ассигнованияләре һәм башка чаралар файдалану турында мәгълүматлар;

д) муниципаль программага муниципаль заказчы керткән үзгәрешләр турында мәгълүмат.

Муниципаль программаларның план һәм хакыйкый нәтиҗә күрсәткечләре арасында әһәмиятле аерма булган очракта, аларга йогынты ясаган факторларга анализ ясала. Анализ вакытында муниципаль заказ бирүче тәэсир итә ала торган эчке факторлар һәм аңа бәйле булмаган тышкы факторлар аерылып күрсәтелә.

5.6. Муниципаль заказ бирүче – муниципаль программаның координаторы интернет челтәрендә муниципаль программаның тулы текстын, муниципаль программаны гамәлгә куюның норматив хокук актларын һәм программа буенча каралган чараларның үтәлешен контрольдә тотуны, шулай ук муниципаль программаны тормышка ашыру барышын, планлаштырылган чорда узачак программа буенча каралган чаралар турында, муниципаль программаның фактта финанслану дәрәҗәсен, төзелгән муниципаль килешүләр хакында, аларның күләмнәре, башкаручылары турында, программа чаралары үтәлешен эксперт тарафыннан тикшерү нәтиҗәләре, муниципаль программаны гамәлгә ашыру буенча конкурслар, мониторинг нәтиҗәләре, муниципаль программаны гамәлгә куюда максатчан индикаторларга ирешүнең нәтиҗәлелеген бәяләү турында(шул ук вакытта бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча да) мәгълүмат урнаштыра. Муниципаль программаны гамәлгә куюда катнашу өчен конкурс турында мәгълүматта:

- конкурс үткәрү шартлары;
- юридик затларның катнашу тәртибе;
- конкурс комиссиясе составы;
- конкурс комиссиясе утырышларының беркетмәләре;
- муниципаль заказчы тарафыннан кабул ителгән карарларга шикаять бирү тәртибе күрсәтелә.